КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 август г.Казань № 1012

Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел
тулуны бәйрәм итү турында

Татар совет язучысы, драматург һәм сәясәт эшлеклесе Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чаралар әзерләү һәм уздыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның декабрендә Татарстан Республикасында Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрергә.
2. Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның кушымта итеп бирелә торган составын расларга.
3. Әлеге оештыру комитетына 60 көн эчендә Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итү чаралары планын эшләргә һәм расларга.
4. Республика “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итәргә.
5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 24 август, 1012 нче
карары белән расланды

Ш.Х.Усмановның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Ихсанова Илсөяр Вазыйх кызы | «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) рәисенең иҗади мәсьәләләр буенча беренче урынбасары, оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әминов Илшат Юныс улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гыймалетдинов Фирдүс Салих улы | «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы директоры (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат Улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) рәисе(килешү буенча) |
| Мөхәммәтшин Рүзәл Фәиз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә караган Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлекчәсе мөдире |

| | |
|---|---|
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Тимерҗанова Мәдинә Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шакиров Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

______________________________